# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Келәр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2025 елның 19 ноябре** **№ 2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Уставының 26 статьясы нигезендә , 2025 елның 19 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде : «2026 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Келәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә,алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын урнаштыру, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 5 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 5 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 5 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар чыгарды:

1. Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлегенең Келәр торак пунктында гражданнар җыенын узган дип , гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карар кабул итәргә: «2026 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең Келәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә,алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын урнаштыру, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү».

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Олы Карамалы авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат такталарына урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Карамалы ав., Үзәк ур., 4 й.

- ТР, Кама Тамагы районы, Бәрлегуҗа авылы, Тукай урамы, 16 йорт, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә , кабул ителгән көннән башлап 10 (ун) көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Карамалы авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Э.М.Мөхәммәтшин